ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.06.2020 г. с. Муслюмово № 286

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының «2020 елга «Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында» 2019 елның 13 ноябрендәге 697 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында ата-аналар түләвенең күләмен формалаштыруга карата алымнарны үзгәртү мәсьәләсе буенча 2020 елның 26 маенда узган киңәшмәдә Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнеханов биргән йөкләмәне үтәү кысаларында, «Татарстан Республикасы иктисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең муниципаль районнар, шәһәр округлары башкарма комитетларының 2020 елның 12 маенда барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла торган «2020 елга мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында»гы карарларына үзгәрешләр кертү турындагы тәкъдиме нигезендә Татарстан Республикасында мәктәпкәчә мәгариф оешмаларын финанслауның норматив принцибын гамәлгә ашыру буенча методик ярдәм күрсәтү максатыннан, Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының «2020 елга «Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турында» 2019 елның 13 ноябрендәге 697 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә:

- 1 пунктның 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 кушымта нигезендә, мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына 2020 елның 1 гыйнварына кадәр кабул ителгән балага ата-ана түләве күләменә (азык-төлек продуктлары бәясеннән тыш) күчеш чорындагы төзәтмә коэффициенты»;

- 2 абзацтагы «Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында балаларны караган һәм караган өчен ата-аналар түләве күләмен» 2 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә расларга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 12 маеннан барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль-мәдәни үсеш буенча урынбасары М. Р. Бәдретдиновага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.Х.Әхмәтов